ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__305____ от «__30__»____03_________2018 г.

Шәһәр һәм район территорияләрен чистарту
буенча санитар- экологик икеайлык
игълан итү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 03 мартында кабул ителгән б-593нче номерлы боерыгын үтәү һәм торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны халыкның экология һәм санитария эпидемиология иминлеге таләпләренә җавап бирә торган хәлгә китерүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр шәһәр һүм район торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгын игълан итәргә.

2. Мамадыш муниципаль район берәмлекләре башкарма комитетларына, Мамадыш шәһәре башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар чистарту планнарын әзерләүне һәм 2018 елның 31 мартына кадәрраслауны;

- икеайлык үткәрү эшләрен яраштыру өчен оператив штаблар оештыруны;

- җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләре, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләре үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү өлешендә җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары эшен активлаштыруны;

- су объектларының су саклау зоналарын, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм кием-салым базарларын, халык күпләп ял итү урыннарын, ял итү базаларын, бакчачылык җәмгыятьләрен һәм гараж кооперативларын, шәхси торак секторы территорияләрен санитар чистарту, контейнер мәйданчыклары төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау чараларын үткәрүне;

- каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрүне;

- терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрүне;

- «Татарстан Республикасы Экологик картасы» геомәгълүмат системасы www.ecokarta.tatar.ru ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мониторингын гамәлгә

ашыруны;

-Мамадыш муниципаль районының “Экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиясенә “ бу боерыкка теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча икеайлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны атна саен, пәнҗешәмбе, 2018 елның 12, 26 апрелендә, 10, 24 маенда бу боерыкка теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча (аңлатма язуын теркәп) Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына кертүне.

3.”ҖЧҖ Мамадыш ТКХ” оешмасына:

Каты көнкүреш калдыкларын аеру һәм күмүне , чүп чыгару өчен махсус машина паркы һәм чүп полигоннары эшен тиешенчә оештырыга тәкъдим итәргә;

4. “Экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиясенә “ Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Мамадыш районы һәм Мамадыш шәһәре буенча территориаль идарәсенә (Маснавиева М.Х.), Мамадыш районы һәм мамадыш шәһәре территориясендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә табигатьне саклау турындагы законнар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны тәкъдим итәргә;

5. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына икеайлык кысаларында үткәрелә торган эшне “Нократ” (“Вятка”) газетасында әледән-әле яктыртып торуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов